**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**20 декабрь 2019 ел** **№ 13**

## Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Айбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 17.08.2018 № 6 карары (13.03.2019 №2 карар редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктта:

а) 3 абзацта " планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы» сүзләрен «урам-юл челтәре элементы элементын һәм (яки) планлаштыру структурасы элементын (кирәк булганда)»сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 нче абзацны түбәндәге редакциядә тасвирларга:

«адресация объекты-капиталь төзелеш объекты, җир участогы яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Айбаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Сафиуллин